ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.03.2019 Олы Кайбыч авылы № 130

**Кайбыч муниципаль районында**
**2019-2023нче елларга**
**кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү**
**Программасын раслау турында**

2007нче елның 24нче июлендә чыккан 209-ФЗ номерлы «Россия Федерация-сендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законы, 2010нчы елның 20нче гыйнварында чыккан 7-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү максатында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР КЫЛА:**

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында 2019-2023нче елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында Программаны расларга (кушымта №1).

2.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләренә, район җирлекләренә, кече һәм урта эшмәкәрлек предприятиеләренә Программаны үтәү чараларын тәэмин итәргә.

3.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 нче елның 11нче апрелендә чыккан «Кайбыч муниципаль районында 2017-2019нчы елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында Программаны раслау турында» карарын гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион

Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Н.Макаров**